**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы карары**

Уразай авылы № 93 "17" апрель 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Советының 01.12.2014 №94 "Әлеге салымнар буенча недоимка һәм бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында" карарына үзгәреш кертү турында (05.11.2015 №17 номерлы карар редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә

Уразай авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Советының 01.12.2014 №94 "Әлеге салымнар буенча недоимка һәм бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында" карарына (05.11.2015 №17 номерлы карар редакциясендә) үзгәреш кертергә, 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле бишенче - алтынчы абзацлар өстәп:

«-җирле салымнар буенча суд приставы - башкарма производствоны тәмамлау турында карар чыгарган очракта, "Башкару эшчәнлеге турында" 2007 елның 02 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында билгеләнгән нигезләрдә башкарма документ түләтүчесен кире кайтару турында карар үтәтүче тарафыннан чыгарылган очракта»;

- гамәлдән чыгарылган җирле салымнар һәм җыемнар буенча, реструктуризация режимында һәм бөлгенлек (банкротлык) процедураларында булган салым түләүчеләргә бурычлардан тыш. "

2. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга, веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштырырга: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http//aznakayevo. tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис : А.М.Шэрифуллина